# Китапны яраталар




Балалар китабы атналыгы - барлык укучы балаларнын бәйрәме. Тагы китапка гашыйк булган кызыксынучан балалар һәм олкәннәр бәйрәме дә.
Кадошкино районы vзәк китап-ханәсендә “Балалар китабы” атналыгы ачылган. Китапханә хезмәткәре Динара Идрис кызы Альмяшева балаларга бәйрәмнен барлыкка килv тарихы турында сойләгән.       Аннары балалар уен программасында бик теләп катнашканнар: хәйләкәр табышмакларга жавап биргәннәр, яраткан әкиятләрен искә тошергәннәр. Балаларга кунакка “Китап патшабикәсе” килгән, бергә китап белән эш итv кагыйдәләре буенча “Әйе - Юк” уенын да уйнаганнар.
Атна дәвамында яшь укучыларны торле чаралар котә.